КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 1 ноябрь г.Казань № 996

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалану алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын һәм онкология авырулары белән интегүче затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларына дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 9 октябрь, 743 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалану алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын һәм онкология авырулары белән интегүче затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларына дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 9 октябрь, 743 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 10 май, 312 нче; 2014 ел,

30 сентябрь, 696 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «8 статьясын үтәү йөзеннән» сүзләрен «8.1 һәм 8.2 статьяларын үтәү йөзеннән» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ нче пункт өстәргә:

«$4^1$. Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына ел саен Татарстан Республикасы территориясендә җайга салынмый торган тарифлар буенча даими йөртүләрнең муниципальара маршрутларда бер километр юл өчен юл йөрүнең уртача кыйммәтен пассажирлар йөртүчеләр тарафыннан даими йөртүләрнең муниципальара маршрутларына билгеләнгән тарифлардан һәм пассажирлар йөртүчеләр саныннан чыгып исәпләп чыгаруны гамәлгә ашырырга. Әлеге юл йөрүнең уртача кыйммәтенең йомгаклау мәгънәсен агымдагы елның 15 декабренә кадәр Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына җибәрергә.»;

әлеге карар белән расланган Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалану алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару  һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын һәм онкология авырулары белән интегүче затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларына дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын компенсацияләү тәртибендә:

5 нче пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Т – Татарстан Республикасы территориясендә җайга салынмый торган тарифлар буенча даими йөртүләрнең муниципальара маршрутларда бер километр юл өчен юл йөрүнең гариза бирү көненә гамәлдә булган уртача кыйммәте.»;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

11 нче пунктның икенче абзацында «компенсация» сүзе алдына «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча банкта яки башка кредит оешмасында (банк яки башка кредит оешмасы аша компенсация алганда) ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп» сүзләрен өстәргә;

12 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Федераль салым хезмәтеннән гариза бирүче яки аның гаилә әгъзалары алган керемнәр турында мәгълүматлар.»;

13 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза бирүченең ризалыгы булганда компенсацияне билгеләү Федераль салым хезмәтендә булган соңгы календарь ел өчен физик затларның керемнәре турындагы мәгълүматлар нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Бу карарның 1 нче пунктындагы унберенче – ундүртенче абзацлары 2020 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин